**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТЕЛӘНЧЕ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
**КАРАР**

“16” ноябрь 2023 ел Теләнче Тамак авылы №14

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлегенең Теләнче Тамак авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Теләнче Тамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2023 елның 30 ноябрендә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авылы үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Теләнче Тамак авылы, Татарстан урамы, 19 йортта билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Теләнче Тамак авыл җирлегенең Теләнче Тамак авылы территориясендә 2024 елда балигъ булган, Теләнче Тамак авыл җирлегенең Теләнче Тамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Татарстан урамы, Теләнче-Тамак авылы буенча видеокүзәтү җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру
- Балалар бакчасы территориясендә балалар мәйданчыгын төзекләндерү (балалар уен элементларын сатып алу, урнаштыру)
- Күп фатирлы йортлар территориясен төзекләндерү
- Теләнче - Тамак торак пунктында милли Сабантуй бәйрәмен оештыру өчен бүләкләр алу;
- Теләнче-Тамак торак пунктында урамнарны яктыртуны ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) сатып алу;
- Теләнче-Тамак авылы Татарстан урамы буенча гомуми файдаланудагы территорияне төзекләндерү

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

2.1 Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларының үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә

3. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
5. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
6. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Нәҗметдинов